**МЕЖРЕГИОНАЛЬНАЯ ОЛИМПИАДА ШКОЛЬНИКОВ «ЮНИОР»**
**ПО ТАТАРСКОМУ ЯЗЫКУ**
**ЗАКЛЮЧИТЕЛЬНЫЙ ЭТАП**
**2022-2023 учебный год**
**7 КЛАСС**

## Критерии оценивания

**Таблица ответов**

| | 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 | 9 | 10 | 11 |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| **1** | X | | | | | | | | | | X |
| **2** | | X | | | | | X | | | X | |
| **3** | | | | X | | | | | X | | |
| **4** | | | X | | X | X | | X | | | |
| | ***задания по 4 балла*** | | | | | | | | | | |

1. *Яу* сүзендә: (4 балл)
**1) 2 тартык, 1 сузык**
2) 2 сузык, 1 тартык
3) 2 сузык кына
4) дөрес җавап юк

2. Кайсы рәттәге сүзләрнең барысында да басым соңгы иҗеккә төшә? (4 балл)
1) кайтма, дәфтәрне, авыл
**2) килдек, дәрестә, урындык**
3) биемә, калын, кибеттән
4) ничәнче, юка, уйлама

3. Кайсы рәттәге сүзләрнең барысында да нокталар урынына а хәрефе языла? (4 балл)
1) ...ешма, халык...ра, берк...дәр
2) ид...рә, мәшәк...ть, зы...лы
3) бит...раф, яш...еш, г...җәпләнә
**4) д...выл, зиф..., мәнфәг...ть**

4. КДУ, КДПУ, РФ, ТР сүзләре сүз ясалышының кайсы ысулы буенча ясалганнар? (4 балл)
1) сүзгә кушымчалар өстәү юлы белән
2) сүзоәрне кушу юлы белән
**3) сүзләрне кыскарту юлы белән**
4) сүзгә яңа мәгънә өстәү юлы белән

5. Җөмләдәге аерып бирелгән фигыльләрнең төркемчәсен билгеләгез: *“Кигән кием ничек туза, яшь гомер шулай уза.”* (4 балл)
1) сыйфат фигыль
2) инфинитив
3) хәл фигыль
**4) хикәя фигыль**

6. Җөмләнең иярчен кисәкләре: (4 балл)
1) аергыч, тәмамлык, хәл
2) тәмамлык, хәл, аныклагыч
3) аергыч, хәл, аныклагыч
**4) җавапларның берсе дә тулы түгел.**

7. Кайсы рәттә җөмләнең өндәү сүзен аера торган өтерләр бар? (4 балл)
1) Кибеттә кызыл, яшел, зәңгәр төсле күлмәкләр бар.
**2) Алинә, кил әле яныма.**
3) Без, җиденче сыйныф укучылары, бүген әдәбият дәресендә булдык.
4) Мин, әлбәттә, яхшы укырга телим.

8. “*Я встретил его в воскресенье”* җөмләсенең дөрес тәрҗемәсен языгыз. (4 балл)
1) Мин аны шимбә очраттым.
2) Мин аның белән якшәмбе көнне өчраштым.
3) Мин аңа якшәмбе көнне шалтыраттым.
**4) Мин аны якшәмбе көнне очраттым.**

9. Баллада ул – (4 балл)
1) драма әсәре
2) шигъри әсәр
**3) лиро-эпик әсәр**
4) чәчмә әсәр

10. «Без – кырык беренче ел балалары» әсәрендә вакыйгалар кайсы елларда төгәлләнә? (4 балл)
1) 1981
**2) 1946**
3) 1941
4) 1957

11. Х.Туфанның «Кайсыгызның кулы җылы?» шигырендә нинди сурәтләү чарасы кулланыла? (4 балл)
**1) кабатлау**
2) метафора
3) ирония
4) дөрес җавап юк

12. Әсәрләрнең авторларын языгыз. (8 балл)
“Милли моңнар” Габдулла Тукай
“Алмачуар” Галимҗан Ибраһимов
“Кем җырлады?” Әмирхан Еники
“Мокамай” Һади Такташ

13. Әсәрләрнең жанрларын языгыз. (8 балл)
“Милли моңнар” шигырь
“Алмачуар” хикәя
“Кем җырлады?” хикәя
“Мокамай” поэма

14. Бирелгән өзекне дәвам итегез, авторын, жанрын языгыз. (5 балл)
“Ишеттем мин кичә: берәү җырлый
Чын безнеңчә матур, милли көй;
Башка килә уйлар төрле-төрле, —
Әллә нинди зарлы, моңлы көй.”

Габдулла Тукайның “Милли моңнар” шигыре

15.  Бу өзек кайсы әсәрдән алынган? Аның исемен, авторын, жанрын языгыз. (5 балл)

“Ләкин бу бәхет тиз арада бик артык авыр бәхетсезлеккә әйләнде. Белмим, атымны кызу каулап яндырганмынмы, белмим, килеп җиткәч, староста белән талашып, туктап тору харап иткәнме? - ни дә булса булган: сабан туеның икенче көнендә *** аякларына баса алмас булды, ашавыннан, эчүеннән калды. Бичаракаем, адәмнән болай акыллырак күзләре белән һәркемгә мөлдерәтеп карап, бер атнага якын ыңгырашып ятты да җомга көн, иртә белән сәгать унда дөньядан үтте.”

Галимҗан Ибраһимовның “Алмачуар” хикәя.

16.  15 биремдә бирелгән әсәрнең төп фикерен языгыз. Әсәрдә нинди тема яктырыла? (10 балл)
Әсәрнең төп идеяләренең берсе – гаделлек. Кеше эгоист булырга тиеш түгел, ул тирә-юньдәгеләрне аңларга тиеш. Автор хайваннарны ярату турында да сөйли.

17. “Ни өчен халкымның мәдәни традицияләрен сакларга кирәк?” дигән тема буенча 10 җөмләдән ким булмаган инша языгыз. (20 балл)